***Муниципаль тур***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ

# ҖАВАПЛАРЫ

(2025-2026 нчы уку елы)

**6 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 58**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Тел уртасы тартыгын билгеләгез. **(2 балл)**
   а) [ғ]
   **ә) [й]**
   б) [х]
   в) [ң]
2. Рәт гармониясенә буйсынмаган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) елан
   ә) төлке
   б) чишмә
   **в) дөнья**
3. Ачык иҗекләрдән генә торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) өчпочмак
   ә) коймак
   б) кыстыбый
   **в) гөбәдия**
4. ***Йомшак*** сүзе күчерелмә мәгънәдә кулланылган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
   **а) йомшак тавыш**
   ә) йомшак юрган
   б) йомшак мендәр
   в) йомшак кәнәфи
5. Искергән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) мәчет
   **ә) алпавыт**
   б) намаз
   в) табигать
6. Ясалма нигезле сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) суык
   ә) алка
   б) бүрек
   **в) кунак**
7. Рәвешне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) оялчан
   ә) чөнки
   **б) әкрен**
   в) матур

8. Сызыкча аша языла торган кисәкчәне билгеләгез. **(2 балл)**

**а) кып**
ә) дөм
б) түгел
в) гына

9. Билгесез үткән заман хикәя фигыльне билгеләгез. **(2 балл)**

а) ашый
ә) аша
б) ашады
**в) ашаган**

10. Җөмләнең иясен билгеләгез. **(2 балл)**

*Кечкенә генә сандыкка бөтен дөнья сыйган.* (Мәкаль)
а) сандыкка
ә) бөтен
**б) дөнья**
в) сыйган

## II. Теоретик бирем.

Сызыклар өстенә тиешле сүзләрне языгыз. **(6 балл)**

Сүзләрнең әйтелешен орфоэпия бүлеге өйрәнә. [э] авазы сүз уртасында һәм сүз ахырында е хәрефе белән белдерелә. Әйтелеше бер, ә язылышы төрле булган сүзләр омофоннар дип атала. Парлы сүзләр сызыкча аша языла. Саннар сүзләр яисә цифрлар белән языла. Ия белән хәбәрдән генә торган җөмлә җыйнак җөмлә була.

## III. Башыгызны эшләтегез.

Кушма сүзләрнең беренче компонентларын уйлап языгыз. **(4 балл)**

| | |
|---|---|
| билбау | бозкискеч |
| баштүбән | байтирәк |

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(6 балл)**

Каждое утро на луг прилетает стайка воробьёв. Я открываю окно. Бросаю им семена, сухой хлеб.

2. Шигырьне укыгыз һәм биремнәрне эшләгез.

ЧАҢГЫ БЕЛӘН ДУС БУЛСАҢ

Һәр ял көнне тауда шуам,
Рәхәт шул чөнки анда.
Кем белә, бәлки, тиздән мин
Булырмын чемпион да.

Чемпион да булмам, бәлки,
Тик шуны яхшы беләм:
Сырхау һәрчак читтә йөри,
Дус булсаң чаңгы белән.

(*Ләбиб Лерон*)

2.1. Сингармонизм законының рәт гармониясенә буйсынмаган сүзләрне күчереп языгыз. **(2 балл)**

**(чемпион, чемпион, һәрчак)** (артык сүз язылса, балл киметелә!)

2.2. Тел арты ассимиляциясе күзәтелгән сүзне күчереп языгыз. **(1 балл) (чөнки)** (артык сүз язылса, балл киметелә!)

2.3. ***Сырхау*** сүзенең синонимнарын языгыз. **(2 балл) авыру, чирләү**

2.4. Исемнең баш килештә килүен таләп итүче бәйлекне күчереп языгыз. **(1 балл) (белән)** (артык сүз язылса, балл киметелә!)

2.5. Урын рәвешен күчереп языгыз. **(1 балл) (читтә)** (артык сүз язылса, балл киметелә!)

2.6. ***Булырмын*** фигыленә морфологик анализ ясагыз. **(3 балл)**

**Булырмын – хикәя фигыль, затланышлы, билгесез киләчәк заманда, I зат, берлек санда, барлыкта, тамыр сүз.**

3. **«Ял көнендә»** дигән темага 8-10 җөмләдән торган инша языгыз. **(12 балл)**